**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Балтач авылы № 16 «25» февраль 2026 ел.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 2014 елның 16 августындагы 91 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» карары белән расланган (18.11.2015 № 15, 16.12.2016 № 44, 23.04.2019 № 131, 03.02.2020 № 157, 12.03.2021 № 23, 06.10.2021 № 35, 01.02.2023 № 76,02.10.2023 № 94, 12.01.2024 № 105, 23.04.2024 № 117,28.11.2024 № 135,09.12.2025 № 9 карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Балтач авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 16.08.2014 елның 91 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» карары белән расланган (18.11.2015 № 15, 16.12.2016 № 44, 23.04.2019 № 131, 03.02.2020 № 157, 12.03.2021 № 23, 06.10.2021 № 35, 01.02.2023 № 76,02.10.2023 № 94, 12.01.2024 № 105, 23.04.2024 № 117,28.11.2024 № 135,09.12.2025 № 9 _карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә 10 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«10 бүлек. КЕРЕМНӘР, ЧЫГЫМНАР, МӨЛКӘТ ҺӘМ МӨЛКӘТИ ХАРАКТЕРДАГЫ ЙӨКЛӘМӘЛӘР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘРНЕ ТАПШЫРУ

1. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан әлеге белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм формада тапшырырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Л.Хәбипов